Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы

КАРАР

№32 23 гыйнвар 2017 ел

Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы башлыгының 2016 елда социаль-икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2017 елга планнары турында хисабы

Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы башлыгының 2016 елгы социаль – икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2017 елга планнары турындагы хисабын тыңлап һәм фикер алышып, авыл җирлеге Советы 2016 елда авыл җирлеге халкы мәнфәгатьләрендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясенең 6.10.2003 елдагы 131-ФЗ номерлы Законы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елдагы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы карары:

1. Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы башлыгы Дәүләтшина Г.Г. 2016 елда авыл җирлегенең социаль – икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2017 елга планнары турында хисапны игътибарга алырга.
2. 2017 елда авыл җирлеген социаль – икътисади үстерүнең төп бурычы булып халыкның тормыш сыйфаты үсешен тәэмин итү санала.
3. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә аерым игътибар бирегез.
4. Авылда яшьләрне ныгыту өчен кредит бирү һәм торак төзелеше өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган программаларның мөмкинлекләрен максималь файдалану.
5. Халыкның тормыш дәрәҗәсен төшерүгә юл куймау һәм гражданнарның социаль хезмәтләргә тигез керү мөмкинлеген тәэмин итү буенча чаралар күрергә.
6. Хокук саклау органнары белән берлектә җәмәгать иминлеге дәрәҗәсен күтәрү һәм җәмәгать тәртибен, гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген һәм дәрәҗәсен ышанычлырак яклауны тәэмин итү буенча алга таба эш алып барырга.
7. Торак пунктларны төзекләндерү, яшелләндерү һәм чистарту, экологик иминлекне тәэмин итү буенча чараларны дәвам итәргә.
8. Авыл җирлеге башкарма комитетына хисап докладында һәм аны тикшергәндә әйтелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне үтәү буенча чаралар планын эшләргә тәкъдим итәргә.
9. Авыл җирлеге Советы аппаратына хисап докладында һәм аны тикшергәндә әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерергә.
10. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http:aksubaevo.tatarstan.ru.
11. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Иске Кыязлы авыл җирлеге Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе: Г. Г. Дәүләтшин